Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Красный Ключ авыл җирлеге составына керүче Пробуждение торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

# КАРАР

2020 елның 27 ноябре № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2020 елның 27 ноябрендә уздырылган «Түбән Кама муниципаль районы Красный Ключ авыл җирлеге Пробуждение торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән, 1 нче төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге (уку йортына йөреп уку) уку студентларыннан тыш; 2 нче төркем инвалидларына һәм 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерларга, күп балалы гаиләләргә 50% түләү белән, 10000 суммасында 2021 елда үзара салым кертү белән килешәсезме. Һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юнәлтү:

- Пробуждение поселогындагы юлларны ремонтлау

«ӘЙЕ» «ЮК»

мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 15 граждан кертелгән, тавыш бирүдә катнашучы гражданнар саны 11 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучы гражданнар тавышлары түбәндәгечә бүленде: «Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 11 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Красный Ключ авыл җирлеге составына керүче Пробуждение торак пунктында гражданнар җыенын узды дип таныргa, гражданнар җыены нәтиҗәләре - дөрес.

2. «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Красный Ключ авыл җирлеге составына керүче Пробуждение торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән, I төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге (уку йортына йөреп уку) уку студентларыннан тыш; 2 нче төркем инвалидларына һәм 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерларга, күп балалы гаиләләргә 50% түләү белән, 10000 суммасында 2021 елда үзара салым кертү белән килешәсезме. Һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юнәлтү:

- Пробуждение поселогындагы юлларны ремонтлау

«ӘЙЕ» «ЮК»

мәсьәләсе буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларына, Красный Ключ авыл җирлеге сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Красный Ключ авыл җирлеге башлыгы И.К.Зәйнетдинов